Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Иске Суркино авыл Советы

КАРАР

8 апрель 2026 ел

№ 15

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл Советының 2022 елның 05 августындагы 53 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлеге сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турында» карарның үз көчен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Иске Суркино авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл Советының 2022 елның 05 августындагы 53 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлеге сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турында» карарның үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Әлмәт районы, Иске Суркино авылы, Үзәк урамы, 77 йорт, Яңа Суркино авылы, Үзәк урамы, 12а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Иске Суркино авыл
җирлеге Башлыгы

Е.В. Якушкин